# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**10.12.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 11 ноябрендә 09:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм irектән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Көчек авылында Казан урамы буенча урнашкан суүткәргеч челтәрләренә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау
2. Көчек авылында Тукай урамы буенча янгын гидранты урнаштыру.
3. Көчек авылы урамнарын кардан чистарту.
4. МТЗ-82 тракторын карап тоту, аңа хезмәт күрсәтү һәм тагылма җиһазлар алу.
5. Көчек авылының 2 нче су башнясы өчен тирәнлек насосы сатып алу һәм урнаштыру.
6. Көчек авылында янгын сүндерү машинасының штаттан тыш хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү.
7. Көчек авылында Бөек Ватан сугышында үлгәннәргә һәйкәл кую.
8. Торак пунктның урам утларын карап тоту өлешендә чаралар (дроссельләрне, фонарьларны сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру).
9. Көчек авылында К.Маркс һәм Яңа урамнарына вак таш җәю.
10. Авыл җирлеге территориясендә уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.
11. Көчек авылы зираты территориясендә авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кисү.
12. Чүп чабу һәм дизель ягулыгы сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 438 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 231 кеше, бу 52,8 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 231 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Көчек авылында Казан урамы буенча урнашкан сууткәргеч челтәрләренә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау

2. Көчек авылында Тукай урамы буенча янгын гидранты урнаштыру.

3. Көчек авылы урамнарын кардан чистарту.

4.МТЗ-82 тракторын карап тоту, аңа хезмәт күрсәтү һәм тагылма җиһазлар алу.

5. Көчек авылының 2 нче су башнясы өчен тирәнлек насосы сатып алу һәм урнаштыру.

6. Көчек авылында янгын сүндерү машинасының штаттан тыш хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү.

7. Көчек авылында Бөек Ватан сугышында үлгәннәргә һәйкәл кую.

8. Торак пунктның урам утларын карап тоту өлешендә чаралар (дроссельләрне, фонарьларны сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру).

9. Көчек авылында К.Маркс һәм Яңа урамнарына вак таш җәю.

10. Авыл җирлеге территориясендә уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

11. Көчек авылы зираты территориясендә авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кисү.

12.Чүп чабу һәм дизель ягулыгы сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан

Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Авыл җирлеге башлыгы Р.А.НУРМӨХӘММӘТОВ

Совет Кучуковского сельского поселения
Кечек авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002526